СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

______________ с. Майдан ______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының 2013 елның 30 апрелендәге 29-156 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә (№1 кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы проекты буенча килүче тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгы Михеев В. В.;

эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Гусева Р. В;

Эшче төркем әгъзалары:

-Шулькова Л. А. - Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчысы;

- Пятнова Е. В. – “Мәйдан балалар бакчасы” мөдире;

– Анохина В.А. - Мәйдан мәдәният йорты мөдире.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы проекты буенча 2018 елның 14 августында 10.00 сәгатьтә Мәйдан КФҮ бинасында (Мәйдан авылы, Совет ур., 55) ачык тыңлаулар үткәрергә.

6. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге халкы тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В. В. Михеев